КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 9 август г.Казань № 672

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында» 2015 ел, 4 март, 132 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында» 2015 ел, 4 март, 132 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«казна учреждениесе эшчәнлегенең максаты булып Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру өлкәсендәге дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру тора дип;»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Казна учреждениесе эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Законда «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» ведомствосы, «Милли икътисад өлкәсендә

башка мәсьәләләр» бүлекчәсе буенча, «Татарстан Республикасы икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыруга каралган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.».

1. 2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесенең уставын әлеге карарга туры китерүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин